*Акча санаганны ярата*

# ЧАМАЛАП КЫНА ЕРАК КИТЕП БУЛМЫЙ

Хуҗалыкларда җитештерелә торган продукциянең үзкыйммәте югары булуында кала һәм артуга бара икән, монда башка факторлар белән беррәттән электр энергиясе өчен түләүләрнең дә өлеше кечкенә түгел. Хәзер күп эшләр электр көченә көйләнгән булуын искә алганда бу табигый да. Әмма тотылган электрның ни чамалырак булуы турында уйланганда, аңа төгәл исәп алып барып, бу эштә ныклы контроль булдырганда һәм шулай итеп акланмый торган чыгымнарны киметү чаралары күрелгәндә электр энергиясен бәрәкәтле генә файдаланырга да мөмкин. Ныклы хуҗалык исәбе булдыру, азрак чыгымнар тотып күп һәм [illegible]анлы продукция җитештерү исәбенә генә манту мөмкин булуы турында сүз алып барганда бу - бердәнбер юл. Хәзер хуҗалыкларда 234 трансформатор подстанциясе бар һәм алардан күпсанлы объектларга электр энергиясе бирелә. Ә һәр объектта берничә электр моторы, электр белән эшли торган башка җиһазлар бар, дистәләгән лампочка яна. Электр энергиясенең күпме тотылуын анык белеп бару бары тик һәр подстанциядә махсус исәпләгеч булганда гына мөмкин. Бу мәсьәләгә җитди игътибар биргән хуҗалыкларда трансформатор подстанцияләре андый исәпләгечләр белән тәэмин ителгән. Синдряков исемендәге, «Киекле», Мичурин исемендәге, «Заветы Ильича», «Әлмәт», «Татарстан», «Кондырча», Кузнецов исемендәге, «Рассвет», «Якты Күл», «1 нче Май», «Төрнәс» хуҗалыкларында, РСУ ярдәмче хуҗалыгында андый исәпләгечләр дә бар, электр хуҗалыгы өчен җаваплы кешеләр дә билгеләнеп, алар электр энергиясе чыгымнары турында отчетларны вакытында биреп баралар. Шуңа да аларда электр энергиясенә киткән чыгымнар да чагыштырмача аз-рак. Мисал өчен, «Заветы Ильича»да бер айда тотылган электр энергиясе өчен түлисе сумма 6 - 7 миллион гына, РСУ ярдәмче хуҗалыгында бу күрсәткеч бик сирәк айларда гына 10 -11 миллионга җитә, механизмнар, электр җиһазлары чагыштырмача күп булган «Төрнәс»тә дә 14 - 16 миллионнан артмый. Дөрес, аның болары да кечкенә сумма түгел. Әмма бүген аеруча борчыганы саннарның башкасы. Күп кенә хуҗалыкларда электр энергиясе өчен түләнәсе суммалар чамадан тыш югары. Әйтик, «Алга»да бу сумма ай саен диярлек 45 - 50 миллион, МСО ярдәмче хуҗалыгында 35 - 40 миллион сумга җыела. «Комбайн», «Таң» һәм кайбер башка хуҗалыкларның да бу төр чыгымнары айдан - айга күпкә ишәя һәм инде ярtышар миллиардтан артып китте. Бу гаҗәп тә түгел, чөнки Муса Җәлил исемендәге, «Чирмешән» хуҗалыкларында бер генә трансформатор подстанциясенең дә электр исәпләгече юк, «Алга»да 8 постанциянең бишесе, «Таң»да бишнең дүртесе, «Үрнәк»тә җиденең, МСО ярдәмче хуҗалыгында унның дүртесе исәпләгечсез. Район буенча бүгенге көндә 69 подстанция исәпләгеч белән тәэмин ителмәгән. Әле булган исәпләгечләрнең күрсәткечләре дә даими язып алынмый һәм нәтиҗәдә «Энергонадзор»га отчет бирелми. Ә бит электр энергиясен сатучылар мондый очракта бик аптырап тормыйлар, еламаган балага имезлек бирмиләр дигән шикелле, энергияне хуҗалыкта булган электр җиһазларының куәтеннән чыгып кына исәплиләр дә, хуҗалыкка чәпәп куялар. Чама белән. Тик бу очракта чама чамадан артмый дигән принцип һич тә хуҗалык файдасына булмый шул. Шуңа күрә ассоциацияләрнең электр энергиясе өчен түлисе бурычлары миллиардлаган сумнарга җыела да инде. Шуңа күрә хәзер хуҗалык җитәкчеләре алдында иң беренче чиратта барлык подстанцияләргә дә электр исәпләгечләр алып кую, аларның күрсәткечләрен даими теркәп баруны кертү бурычы куела. Сүз дә юк, берьюлы берничә исәпләгеч сатып алу җиңел булмаячак, әмма беренче чиратта иң киеренке участоклардагы подстанцияләрне генә булса да исәпләгечләр белән тәэмин итү чарасын күрми ярамый. Бер үк вакытта эчке хуҗалык исәбе кысаларында подразделениеләр (фермалар, гаражлар, мастерскойлар һ.б.) арасында энергия чыгымнарына ныклы исәп - хисап булдыру турында да уйларга кирәк. Ул хакта сүз дә аерым әле.

**Р.САТДАРОВ,**
**«Гостехнадзор» инспекциясе начальнигы.**



**Таныш булыгыз: рәсемдә «Норлатнефть» НГДУсы нефтьчесе Якуб Әбдрәхимов. Идарәнең скважиналарга җир асты һәм капиталь ремонт үткәрү цехында өлкән оператор ул. Хезмәт стажы күптән инде бер дистә елдан артып китте. Тырышлыгы, үҗәтлеге исә башкалар көнләшерлек.**

**Н.КВАШНИНА фотосы.**

## *Газета укучы фикере*

### «Дуслык» - журналдай

«Дуслык» район газетасы якын дустым кебек минем. Сагынып, зарыгып көтеп алам мин аны. Газетаны беренче битеннән алып дүртенчесенә кадәр бер генә хәбәрне дә калдырмыйча укып барам. Соңгы вакытта «Дуслык»ны кулыма алуга ук аның бизәлешенә игътибар итәм. Элек чыга торганнары белән аермасы җир белән күк арасыдай аның. Нинди генә формалар, төсләр, рәсемнәр файдаланылмый хәзер анда. Журналдан бер дә ким түгел инде менә. Бу мөмкинлекләр редакция хезмәткәрләренең яңа җиһаз - компьютерлар белән оста эш итә белүләре нәтиҗәседер дип уйлыйм. Афәрин, дуслыклылар, газетаны тагын да эчтәлеклерәк, бизәлеше ягыннан матуррак итү өчен армый, талмый эшләгез. Уңышлар сезгә.

**С.ФӘТХЕТДИНОВА,**
**хәбәрче.**
**Яңа Әмзә авылы.**

*Яңалыклар*

## «Музыка баскычларында»

Шәһәр музыка мәктәбендә үткән «Музыка баскычларында» кичәсе мәктәпнең 100гә якын беренче сыйныф укучысы өчен күңелдә уелып калырлык булды. Җырлы - биюле бу бәйрәм бүләкләргә дә бай иде. Балалар шатлык - сөенечә тулы бу чара музыка мәктәбе бинасының тузганлыгын, кысанлыгын да оныттырды хәтта.

*Хезмәт коллективында*

# Хуҗалык исәбеннән - өстәмә керемгә

**«Норлатнефть» НГДУсы цехлары быел эчке хуҗалык исәбендә эшли башлады. Яңа режимга күчү чорында мәшәкатьле зур эш алып барылды. Аның тәртибе, барышы, беренче нәтиҗәләре турындагы мәсьәләләргә ачыклык кертүне үтенеп безнең корреспондентыбыз НГДУның хезмәт һәм хезмәткә түләү бүлеге начальнигы В.М.Петровага мөрәҗәгать итте.**

- Цехларны эчке хуҗалык исәбенә күчерүнең максаты чыгымнарны киметү йөзеннән производство резервларын табу һәм файдалану буенча һәр цехның кызыксынучанлыгын күтәрүдән гыйбарәт. Бүгенге көндә 1нче, 2нче, 3нче нефть һәм газ чыгару цехлары, ЦППД, ЦКППН, ПРЦЭО, ПРЦЭЭ, ЦКПРС, ЦНИПР, ЦАП, УПРПП, УТТ хуҗалык исәбенә күчерелде. Анда барлыгы 1365 эшче исәпләнә - бу НГДУдагы барлык кешенең 70 процентын тәшкил итә.

НГДУ белән цехлар арасында үзара хуҗалык исәбендәге мөнәсәбәтләр башлангыч оешмаларның хуҗалык исәбе турындагы положениедә һәм хезмәттәшлек турында килешүдә каралган. Цехлар һәм аларның участоклары арасында үзара җаваплылык НГДУның гамәлдәге хуҗалык исәбендәге дәгъвалар системасы нигезендә билгеләнә. Гаепле дип табылган цех өчен хуҗалык исәбеннән кергән керем киметелә. Аерым гаепләләр өчен дә шундый ук чаралар каралган, шуңа өстәп КТУ киметелә, дисциплинар шелтә белдерелә. Өченче квартал нәтиҗәләре буенча нефть чыгару күләме артты, производство ресурслары экономияләнде, шул сәбәпле хуҗалык исәбендәге керем алынды. Ахыр нәтиҗәгә өлеш керткән һәр эшче төп хезмәт хакына өстәп 295 әрмең сум акча алды. Цехлар арасында А.Н.Саватников җитәкчелегендәге беренче нефть һәм газ чыгару цехы иң күп керем алучы икәнлеге ачыкланды - аның кереме гомуми керемнең 17 процентын тәшкил итә.

Бүгенге производство күрсәткечләре төшү, икътисади тотрыксызлык шартларында идарәдә производствоны финанс яктан нык-лы юлга бастыру төп бурыч булып тора. НГДУ белгечләре бу факторны аңлап эш итәләр. Предприятие карары нигезендә баш белгечләр составында комиссия төзелде. Ул цехлар арасында хуҗалык исәбе нигезендә эшләү системасының кертелүенә һәм алга китешенә йогынты ясый, финанс мәсьәләсендә бүлекчәләрнең эшчәнлеген тикшерә, эчке икътисади механизм тәртибен төзи һәм аны цехлар игътибарына җиткерә.

НГДУда нефть чыгаруда чыгымнарны киметү өчен байтак кына чаралар эшләнә. Шуларның берсе - чыгымнарны азайтучыларны, матди-техник, ягулык-энергетик һәм хезмәт ресурсларын экономияләүчеләрне премияләү турында махсус карар чыгарылды. Анда икътисади яктан нәтиҗәле булган һәр чараны акчалата бүләкләү күздә тотыла. Бу һәр хезмәткәрнең, эшченең кызыксынучанлыгын арттыра: алар системалы рәвештә файдаланылган ресурслар исәбен алып баралар, контроль- үлчәү приборлары күрсәткече ярдәмендә керә, саклана һәм файдаланыла торган ресурсларны контрольдә тотуны гамәлгә ашыралар, башкарыла торган эшләрнең сыйфатын да тикшерәләр.

Йомгаклап әйткәндә, цехларны эчке хуҗалык исәбенә күчерү предприятиегә дә, бу процесста катнашучы һәр эшчегә дә файдалы дияргә мөмкин.

# Хезмәттәшем

Ябалак - ябалак ап - ак кар ява. Иртәнге тынлыкны бозып кар өстеннән берәү килә. Ак кар эсләрендә беренче эзне кем сала - әлбәттә, савучы. Әлфия Сәлахова менә ике дистә елга якын инде «Татарстан» КХАсында сыерлар сава. Әйе, ферма сукмагына беренче аяк атлавына 20 елга якын вакыт узган бит инде. Кайчандыр урта мәктәпне тәмамлауга кыюсыз гына ферма бусагасыннан атлап кергән кыз бүген шулай колхозыбызның уңган, тәҗрибәле савучысы булып җитеште. Әлбәттә, терлекче хезмәте җиңел түгел. Шул гомер эчендә авырлыгы да, кыенлыклар да булгандыр. Баштагы мәлдә өлкән хезмәттәшләренең ярдәмен тоеп, киңәшләрен тыңлап эшләргә туры килде аңа. Әмма, ничек кенә булмасын, Әлфия эшен күңел биреп, яратып, вакыт узсын дип түгел, булсын дип башкарды. Рәсеме Мактау тактасыннан төшмәде, исеме газета битләрендә дә урын алды. Колхоз идарәсе тарафыннан кыйммәтле бүләкләр белән бүләкләнеп килде. Ничә еллар авыл Советына депутат итеп тә сайланды. Әйе, мондый хөрмәткә хезмәтен сөеп башкарган, югары күрсәткечләргә ирешкән кеше генә ия була ала. Әнә шулай хезмәт мәшәкатьләре белән күпме гомер узганы сизелми дә калган...

Әлфиянең гаилә тормышы да бәхетле булды. Ире Рафыйк колхозның уңган механизаторы. Тырышлыгын, булдыклылыгын күреп колхоз идарәсе аңа ферма мөдире вазифасын йөкләде. Рафыйкка эшне оештыра белү, таләпчәнлек, төгәллек кебек сыйфатлар хас. Иртә - кич һәрвакыт савучылар янында ул. Гаиләдә өч бала үсте. Илнур үткән ел 11 нче сыйныфны тәмамлады. Миләүшә мәктәптә 8 нче сыйныфта укый, кечкенә Айгөл балалар бакчасына йөри. Сүз уңаеннан шуны да әйтим, Илнур дигәннән, егет шушы көннәрдә хәрби хезмәткә китәчәк. Аның исән - имин хезмәт срогын тутырып туган авылына кайтуын телик. Изге юллар сиңа, Илнур! Солдат бурычыңны намуслы үтә, ә өйдә синә тату гаиләгез көтә.

**З.ИСМӘГЫЙЛОВА.**

## Безгә язалар

# Каникул бушка узмады

Көзге каникулда оештырылган профиль лагерьга төрле авыл һәм шәһәр мәктәпләрендә укучы 72 бала җыелган иде. Анда безнең белән гаҗәеп оста укытучылар шөгыльләнде. Безгә бирелә, өстәмә белемнәр алу, үткәннәрне кабатлау, үзебезне төрле яктан күрсәтү мөмкинлеге тудырылган иде.

Лагерьның программасы бай эчтәлекле булды: танышу кичәсе, КВНнар, спорткомплекста төрле спорт ярышлары, дискотекалар оештырылды. Төрле экскурсияләрдә булдык, үзебезне кызыксындырган сорауларга җаваплар таптык. Төрле әңгәмәләр барышында районыбызның олы шәхесләре белән таныштык.

Бу өч көн безнең өчен бик истәлекле һәм истә калырлык иде. Норлатның кунакчыл интернат мәктәбендә яшәгәндә бер-беребезгә тизияләшеп яңа дуслар таптык һәм алга таба да хәбәрләшеп торырга сүзләр куештык. Кызганыч, санаулы вакыт бик тиз үтә, безгә дә аерылышырга вакыт җитте. Аны шулай кызыклы һәм бай итеп оештырган кешеләргә, тәмле ашлары белән сыйлаучыларга олы рәхмәтебезне җиткерәсебез килә. Алар киләчәктә дә оештырылсын иде.

**И.ГАЛИУЛЛИНА,**
**Л.ЗӘЙНЕТДИНОВА,**
**Киекле мәктәбенең «Каләмдәш» клубы.**

## Видеопиратларга - кайнар сезон

ТР Министрлар Кабинеты бу елның сентябрь аенда «Татарстан Республикасы территориясендә кино һәм видеопродукцияне тарату турында» карар кабул иткән иде. Анда «ТР территориясендә кино, видеопродукцияне тиражлау, прокатка һәм арендага бирү, видеотекалар, прокат пунктлары һәм сәүдә челтәрләре аша таратуга бәйле эшчәнлекне лицензиялау турында» һәм «Дәүләт теркәү прокат таныклыгы турында» Положениеләр расланды. Күптән түгел аны гамәлгә ашыру турында документ район хакимияте каршындагы кулланучылар хокукын яклау комитеты игътибарына да җиткерелде.

Положениенең асылы түбәндәгедән гыйбәрәт: 15нче ноябрьдән кино- видеоэшчәнлек белән шөгыльләнүче физик һәм юридик затларның кино, видеопродукциянең барлык төрләрен тарату, демонстрацияләүгә республика лицензияләре булырга тиеш. Бусы бер. Икенчесе - реализацияләнә, таратыла торган видеопродукциягә РТның Дәүләт киносы пломбалары салынган булуы таләп ителә. Аңлашыла ки, болар һәммәсе дә әлеге продукция таратучыдан өстәмә чыгымнар сорый. Ә кайберәүләргә кино, видеопродукцияне тарату белән шөгыльләнергәме, юкмы дигән нигезле уйларга бирелергә туры килмәгәе.

## КЫЗЛАР КҮҢЕЛЕН НИЧЕК ЯУЛАРГА?

*Егетләр колагына*



* Елмаегыз! Хатын - кыз пөхтә киенгән, әйбәтләп кырынган, елмаючан ир - егетләргә игътибар итә.

* Хатын - кызга кыска, әмма үткен караш ташлау - «игътибар итү, бу - мин!» дигән сүз.

* Бераз озаграк карап торуны хатын - кыз кызыксыну һәм чакыру дип кабул итә.

* Ике арада симпатия тууын сизгәч, беренче адым ясала. Урындыгызны аңа якынрак шудыруы тыныч үтсә, яңа адым ясарга мөмкин.

* Битараф булып кыланыгыз. Бу кыяфәт сезне «серле» итә. Хатын - кыз бу «серне» ачарга омтылачак. Ләкин сезнең «битарафлык» юралмый гына...

* Хисләрегезне белдерегез. Монда арадашчы кирәкми, тәвәккәл, ягымлы булыгыз һәм кыю эш итегез. Хатын - кызлар «җебегән» ирләрне өнәми.

# Сорагыз - җавап бирәбез

## Берничә хатын белән

*Дөресме икән ул, Ингуш республикасы Президенты Руслан Аушев берничә хатын белән торуны рөхсәт итә торган указга кул куйган, диләр.*

Ингушетиядә 1993 елда ике хатын белән торган өчен җинаять җаваплылыгы беркетелгән иде. «Әгәр кешенең ике - өч фатир тотарга хакы бар икән, ни өчен ике хатын белән тору хокукына да ия түгел ул? Бу бит кеше хокукларын турыдан - туры бозу булып тора»,- дип шаярткан иде ул чагында Президент Аушев.

Чынлыкта исә Аушевның Указы ингуш халкының аз санлы булуы уңаеннан килеп чыккан иде. Россиядә ингушлар нибары 300 мең чамасы. Моннан тыш, күп хатынлык мөселман кануннарына туры килә бит. Ә ингушлар - мөселманнар.

## Ленинның ике кепкасы

*Ленинның ике кепка белән төшкән сурәт - һәйкәле бар диләр: берсе - башында, икенчесе - кулында имеш. Дөресме бу, әллә анекдот кынамы?*

Чынлап та, мондый сәер һәйкәл Ишим шәһәренең (Төмән өлкәсе) вокзал буе мәйданында берничә дистә ел торды. Партия җитәкчеләреннән тыш, бу хәлне беркем дә күрмәде бугай. Моның өчен күпләрнең урыннарыннан «очу» мөмкинлеге дә бар иде бит, югыйсә. Җирле халыкның әйтүенчә, Ильич һәйкәлен ике кепкалы итеп ясау - читтән килгән эчкече скульпторның ялгышлыгы.

Икенче бер юлбашчының Ясная Полянадагы һәйкәле тарихы да гаҗәп бит. Л.Н.Толстойның кызы Александра Львовна нигез салган мәктәп алдында Сталинның өстенә шинель кигән, кулына трубка тоткан һәйкәле була. КПССның XX съездыннан соң бу монумент белән нишләргә инде, дигән сорау килеп баса: алып ташларгамы яки... Авыр хәлдән чыгу юлын табалар - Сталинның башын һәм трубкасын кисеп алалар да Ленинның башын чәпәп куялар. Шушы көнгә кадәр тора әле ул: генералиссимус шинеле кигән Владимир Ильич. Алга сузып, нәрсәдер сорап торган уң кулына тимиләр, ә «кипкән» сул кулына... кепка тоттыралар. Шулай итеп, Ста - Ле - нин һәйкәле килеп чыга.

## Чит илгә китәсем килә

*Редакциягә, исемнәрен әйтмичә генә, шушы мәсьәләдә аңлатма бирүне сорап язган хатлар да килә.*

РФ тышкы эшләр министрлыгының консуллык хезмәтендә әйтүләренчә, «исемсез»ләрнең читкә чыгу ихтималы аз. Чит дәүләттә яшәүче кардәш - туганнарыннан чакыру хаты булганнарга бу эш гадирәк. Мондый очракта шул чакыру кәгазе белән ОВИРга мөрәҗәгать итү җитә. Әгәр туганнарың булмаса, визасыз гына кереп була торган берәр илгә (Кипр яки Төркия) барып, шундагы иммиграция хезмәте аша гражданлыкка ия булырга яки паспорт алырга мөмкин. Әлегә шанс зур түгел. Әмма, әгәр кеше теге яки бу тармакта сирәк очрый торган квалификацияле белгеч булса, аның мөмкинлеге зуррак.

# КОТЛЫЙБЫЗ!

Некрасовка поселогында яшәүче бабабыз **Һади** һәм әбиебез **Миңсылу Мусиннарны** 70 яшь тулу уңае белән кайнар котлыйбыз.

Әби - бабай бит ул өйнең яме,
Ә тормышта олы бер терәк.
Сәламәт булыгыз, әби - бабай,
Сез бит безгә бик кирәк.

**Изге теләкләр белән оныклары Марат, Ринат.**

## Алтын туегыз белән!

*Киекле авылында яшәүче кадерле әти - әниебез - **Исхак Исмәгыйль улы** белән **Затия Зыятдин кызы Әһлиуллиннарның** бергә гомер итә башлауларына 50 ел.*

*Кадерле әтиебез һәм сөекле әиебез! Сезне алтын туегыз белн ихлас күңелдән котлыйбыз, безне куандырып, барыбыздан игелекләр генә күреп тагын озак еллар тигез гомер кичерсәгез иде.*



*Гомер буе язсын иде безгә,*
*Әти - әни, диеп дәшәргә.*
*Кайгы күрми, бәхет - шатлык белән*
*Бергә - бергә озак яшәргә.*

***Барлык балалары исеменнән төпчек кызлары Дания.***

## Белдерүләр

### САТАБЫЗ

**Мәрмәр плитәләр. Язуны бер - ике көн эчендә башкарабыз. Бәясе - килешү буенча**. Адрес: Ленинградская ур.,14.

***

**1982 нче елгы «Москвич - 2140», әйбәт хәлдә, бәясе 7 млн. сум, сатулашырга була.** Адрес: Дружба ур., 69 - 46.

***

**Бер бүлмәле фатир**. Тел.: 5 - 40 - 88.

***

**Өч бүлмәле фатир, (базы бар), гараж һәм 1996 нчы елгы ВАЗ - 2106**. Тел.: 5 - 16 - 64.

***

**Кулланышта булган велюр почмак, 10 метрлы келәм, 46 - 48 нче размер мутон тун, тартмасы белән ишек.** Адрес: Космонавтлар ур., 31а - 2.

***

**Ашыгыч рәвештә матрицалы «Epson LX - 300» принтеры, төсле Hewlett Packard «Deckjeet 870 C» төсле принтеры, медисентизатор «форманта» (32 инструмент, эффект), Samsynq «SyncMaster3», цифрлы ревербератор - стерео һәм ПК компьютерына төрле комплектлаучылар**. Тел.: 5 - 26 - 19 (18 сәг.тән 21 сәг. кадәр).

***

**1996 нчы елгы ак төстәге ВАЗ - 21099, 30 мең километр юл үткән.** Адрес: Нефтьчеләр ур., 9 - 16, кич белән.

***

**ВАЗ - 2106, бәясе килешү буенча**. Төрнәс авылында Васин Александрга мөрәҗәгать итәргә.

***

**1996 нчы елгы ВАЗ - 21061. ОСТО район комитетына (ДОСААФ) мөрәҗәгать итәргә**. Тел.: 2 - 25 - 80 (эш), 5 - 17 - 45 (өй).

**«Норлат - Октябрь АТПсы» АҖнә ашыгыч рәвештә йөк машинасына Е категорияле шоферлар, газ һәм электр белән эретеп ябыштыручылар кирәк.**

### Идел Буе региональ наркология үзәге

*Алкогольгә бәйлелектән һәм тәмәке тартудан бер сеанста кодлаштыру.* ***Табиб М.Б.Багрянцев.***

**Бездә генә!**

**Тулы анонимлык. Индивидуаль якын килү. Дәвалау барышында пациентның туганнарына да катнашырга рөхсәт ителә. Белешмә бирелә. Консультация, әңгәмә, кодлаштырудан соң күзәтү һәм ярдәм - бушлай!**

**Язылу һәм әңгәмә дәвалау көнне, җомга көне 5 декабрьдә көндезге сәгать 2дә район мәдәният йорты бинасында уздырыла.**

РФ Сәламәтлек саклау министрлыгыннан 1995 елның 16 гыйнварында бирелгән № 00164 - 30 лицензия.


БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**
МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА.**

Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.

"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.

Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19.

Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм җаваплы сәркәтип - 2-18-67, авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар, хатлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.

*Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.*

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2338 данә.